КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 18 ноябрь г.Казань № 1017

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 декабрь, 1305 нче карары белән расланган 2023 – 2025 елларда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«2023 – 2025 елларда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планын раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 декабрь, 1305 нче карары белән расланган 2023 – 2025 елларда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

2023 ел, 27 март, 364 нче; 2023 ел, 28 июнь, 764 нче; 2023 ел, 24 октябрь, 1342 нче, 2023 ел, 22 декабрь, 1669 нчы; 2024 ел, 4 май, 294 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планына (алга таба – Кыска вакытлы план) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кыска вакытлы планның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Кыска вакытлы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасында торак фондын саклап калу, торгызу һәм аның сыйфатын яхшырту;

гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм.

Кыска вакытлы планның төп бурычлары:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

озак чыдамлы материаллар һәм ресурсларны саклый торган технологияләрне кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләр һәм комплекслылык куллану.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру срогы: 2023 – 2025 еллар.

2023 елда Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру 4,3 млн.кв.метр гомуми мәйданлы 726 күпфатирлы йортта 158 105 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Кыска вакытлы планга 2024 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган 34 902,0 кв.метр гомуми мәйданлы дүрт күпфатирлы йортка проект документациясен эшләү кертелде.

2024 елда Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру 4,6 млн.кв.метр гомуми мәйданлы 751 күпфатирлы йортта 166 803 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Кыска вакытлы планга гомуми мәйданы 190,5 кв.метр булган бер күпфатирлы йортка проект документациясен эшләү кертелде, аларны капиталь ремонтлау 2025 елда планлаштырыла.

2025 елда Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру 4,6 млн.кв.метр гомуми мәйданлы 715 күпфатирлы йортта 166 434 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Кыска вакытлы планга 2026 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган 49 543,9 кв.метр гомуми мәйданлы дүрт күпфатирлы йортка проект документациясен эшләү кертелде.

Кыска вакытлы план үтәлешенең планлаштырыла торган күрсәткечләре:

Татарстан Республикасы буенча тулаем – Кыска вакытлы планга 1 нче кушымтада;

Кыска вакытлы планны үтәүдә катнашучы муниципаль берәмлекләр киселешендә – әлеге Кыска вакытлы планга 2 нче кушымтада китерелде.»;

Кыска вакытлы планның IV һәм V бүлекләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Кыска вакытлы план үтәлешенең планлаштырыла торган күрсәткечләре.
2023 – 2025 елларда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау күләмнәре

| Т/с | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | бар-лыгы | шул исәптән | | |
| | | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Түбә ремонтлау, шул исәптән җилләми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп ясау, өй түбәсенә чыгу урыннарын ясау | мең кв.метр | 880,5 | 294,1 | 317,7 | 268,7 |
| 2. | Электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су чыгару буенча йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән: | мең метр | 2 185,0 | 720,3 | 867,7 | 597,0 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | мең метр | 561,3 | 182,6 | 169,7 | 209 |
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 707,7 | 267,8 | 278,4 | 161,5 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | мең метр | 600,2 | 186,1 | 272,8 | 141,3 |
| 2.4. | су чыгару | мең метр | 307,6 | 80,5 | 143,7 | 83,4 |
| 2.5. | газ белән тәэмин итү | мең метр | 8,2 | 3,3 | 3,1 | 1,8 |
| 3. | Коммуналь хезмәтләр (җылы-лык энергиясе, кайнар һәм салкын су, газ) бирү өчен кирәкле ресурсларны кулла-нуны исәпкә алу буенча күмәк (гомуми йорт) приборларын урнаштыру яки алыштыру | данә | 70 | 23 | 26 | 21 |
| 4. | Җылылык энергиясен куллану белән идарә итү узелларын һәм аны көйләү узелларын урнаш-тыру | данә | 55 | 27 | 21 | 7 |
| 5. | Лифтларны алыштыру | данә | 942 | 257 | 235 | 450 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын ремонтлау | мең кв.метр | 51,7 | 13,4 | 18,6 | 19,7 |
| 7. | Фасадны ремонтлау | мең кв.метр | 1 415,1 | 497,2 | 476,4 | 441,5 |
| 8. | Фасадны җылыту | мең кв.метр | 574,4 | 167,1 | 263,1 | 144,2 |
| 9. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | мең куб.метр | 6,6 | 0,7 | 2,9 | 3,0 |
| 10. | Күпфатирлы йорттагы подъездларны ремонтлау | мең кв.метр | 80,7 | 25,9 | 19,9 | 34,9 |
| 11. | Күпфатирлы йортны янгыннан саклау системасын ремонтлау | мең кв.метр | 72,9 | 39,7 | 30,8 | 2,4 |
| 12. | Вентиляция каналларын һәм төтен чыгу юлларын ремонтлау | мең кв.метр | 7,1 | 2,2 | 2,1 | 2,8 |
| 13. | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | данә | 2 192 | 726 | 751 | 715 |
| 14. | 2023 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | данә | 720 | 720 | 0 | 0 |
| 15. | 2024 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | данә | 751 | 4 | 747 | 0 |
| 16. | 2025 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | данә | 715 | 0 | 1 | 714 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 17. | 2026 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | данә | 4 | 0 | 0 | 4 |

Кыска вакытлы планга кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры әлеге планның 3 нче кушымтасында китерелде.

## V. Ресурслар белән тәэмин ителеше

Кыска вакытлы планны финанслау чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) җирле бюджет акчалары, торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак-төзелеш кооперативлары яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яки күпфатирлы йорттагы бина милекчеләренең акчалары тора.

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме 21 944 684 031,67 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты – 3 869 323 014,47 сум;

җирле бюджетлар – 3 223 727 554,0 сум;

торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативлары әгъзаларыннан яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларыннан яисә күпфатирлы йортлардагы торак милекчеләреннән – 14 851 633 463,2 сум;

алардан Кыска вакытлы план чараларын гамәлгә ашыруга:

2023 елда:

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме 6 260 526 645,92 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты – 1 140 771 614,47 сум;

җирле бюджетлар – 1 078 937 554,0 сум;

торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативлары әгъзаларыннан яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларыннан яисә күпфатирлы йортлардагы торак милекчеләреннән – 4 040 817 477,45 сум;

2024 елда:

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме 8 342 759 773,45 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджеты – 1 364 275 700,0 сум;

җирле бюджетлар – 1 072 210 000,0 сум;

торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативлары әгъзаларыннан яки башка махсуслаштырылган кулланучылар

кооперативларыннан яисә күпфатирлы йортлардагы торак милекчеләреннән – 5 906 274 073,45 сум;

2025 елда:

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме 7 341 397 612,3 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән чаралар:

Татарстан Республикасы бюджеты – 1 364 275 700,0 сум;

җирле бюджетлар – 1 072 580 000,0 сум;

торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак төзелеше кооперативлары әгъзаларыннан яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларыннан яисә күпфатирлы йортлардагы торак милекчеләреннән – 4 904 541 912,3 сум.

Шул ук вакытта кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру кысаларында кыска вакытлы планны финанслауның 50 проценттан артыгы Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән ел саен энергияне сак тоту эшләрен башкаруга җибәрелә.

2023 – 2025 елларда күпфатирлы йортларны
капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме

| Т/с | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару исемлеге | Суммасы, млн.сум | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Түбә ремонтлау, шул исәптән җылыми торган түбәне җиллләнә торган түбә итеп ясау, өй түбәсенә чыгу урыннарын ясау | 5 475,0 | 1 643,6 | 2 199,2 | 1 632,2 |
| 2. | Электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү буенча йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән: | 5 354,7 | 1 408,0 | 2 201,7 | 1 745,0 |
| 2.1. | электр белән тәэмин итү | 874,6 | 255,0 | 270,5 | 349,1 |
| 2.2. | җылылык белән тәэмин итү | 2 207,5 | 596,0 | 904,8 | 706,7 |
| 2.3. | су белән тәэмин итү | 1 150,5 | 279,8 | 522,0 | 348,7 |
| 2.4. | су чыгару | 1 110,9 | 272,8 | 500,1 | 338,0 |
| 2.5. | газ белән тәэмин итү | 11,2 | 4,4 | 4,3 | 2,5 |
| 3. | Коммуналь хезмәтләр (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, газ) бирү өчен кирәкле ресурсларны куллануны исәпкә алу буенча күмәк (гомуми йорт) приборларын урнаштыру яки алыштыру | 16,4 | 4,1 | 5,8 | 6,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Җылылык энергиясен куллану белән идарә итү узелларын һәм аны көйләү узелларын урнаштыру | 59,9 | 21,6 | 27,8 | 10,5 |
| 5. | Лифтларны алыштыру | 3 341,1 | 892,9 | 879,5 | 1 568,7 |
| 6. | Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын ремонтлау | 110,0 | 45,8 | 43,1 | 21,1 |
| 7. | Фасадны ремонтлау | 3 802,6 | 1 220,0 | 1 265,8 | 1 316,8 |
| 8. | Фасадны җылыту | 2 414,0 | 622,7 | 1 207,0 | 584,3 |
| 9. | Күпфатирлы йортның фундаментын ремонтлау | 50,9 | 16,4 | 22,5 | 12,0 |
| 10. | Күпфатирлы йорттагы подъездларны ремонтлау | 201,3 | 66,5 | 66,9 | 67,9 |
| 11. | Күпфатирлы йортны янгыннан саклау системасын ремонтлау | 64,9 | 26,7 | 30,1 | 8,1 |
| 12. | Вентиляция каналларын һәм төтен чыгу юлларын ремонтлау | 48,9 | 11,0 | 23,0 | 14,9 |
| 13. | Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 301,8 | 85,4 | 114,1 | 102,3 |
| 14. | 2023 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 192,6 | 192,6 | 0,0 | 0,0 |
| 15. | 2024 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 258,5 | 3,2 | 255,3 | 0,0 |
| 16. | 2025 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 242,1 | 0,0 | 1,0 | 241,1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 17. | 2026 елда капиталь ремонт үткәрү планлаштырылган күпфатирлы йортларга проект документациясен эшләү һәм капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү | 10,0 | 0,0 | 0,0 | 10,0 |
| 18. | 2014 елның 1 июненә кадәр куелган (алыштырылган) күпфатирлы йортлардагы коммуналь ресурсларны куллану исәбен алуның күмәк (гомумйорт) приборларын урнаштыру (алыштыру) | 3,1 | 3,1 | 0,0 | 0,0 |
| | (торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак-төзелеш кооперативлары яки махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яисә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән генә) | | | | |
| | Барлыгы* | 21 944,7 | 6 260,5 | 8 342,8 | 7 341,4 |

*2014 елның 1 июненә кадәр урнаштырылган (алмаштырылган) күпфатирлы йортлардагы коммуналь ресурсларны куллануны исәпкә алуның күмәк (гомумйорт) приборларын урнаштыруга (алмаштыруга) финанс чараларына ихтыяҗ күләмен исәпкә алмыйча (торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак-төзелеш кооперативлары әгъзалары яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яисә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән генә).

Капиталь ремонт үткәрү кыйммәте күрсәтелгән күпфатирлы йортлар исемлеге Кыска вакытлы планга 4 нче кушымтада китерелде.

Күпфатирлы йортларда 2014 елның 1 июненә кадәр урнаштырылган (алыштырылган) коммуналь ресурсларны куллануны исәпкә алуның күмәк (гомуми йорт) приборларын урнаштыруны (алыштыруны) финанслау күләме әлеге Кыска вакытлы планга 5 нче кушымтада китерелде (торак милекчеләре ширкәтләре, торак кооперативлары, торак-төзелеш кооперативлары яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары әгъзалары яки күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре акчасы исәбеннән).»;

Кыска вакытлы планга 1 – 4 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин